| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.11.2022 № 1188-п

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында

Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында” 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә Мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның , Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасында формалашкан “Алга” һәм “Тимер” батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) һәм гаиләләрен (гаилә әгъзаларын) түләүләрдән тулысынча азат итәргә:

– Саба муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен;

– Саба муниципаль районы мәгариф оешмаларында мәктәптәге туклану өчен.

2. Мәгариф учреждениеләренә, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесенә:

2.1. хәрби комиссариаттан тәрбияләнүче һәм белем бирү оешмасында укучының ата-анасының хәрби хезмәткә чакырылуы турында белешмә күчермәләре яисә хәрби частьтан хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар тарафыннан махсус хәрби операция биремнәрен үтәү турында белешмә күчермәләре яисә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән шартларны һәм фактларны раслаучы башка документлар нигезендә ташламалар бирергә.

2.2. махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта ярдәм чараларын алуга дәгъва кылучы затларны һәм ташламаны гамәлдән туктатуны ачыклау максатыннан хәрби комиссариат белән хезмәттәшлекне алдан карау;

3. “Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына” әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чаралар кабул ителүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар , Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр, Татарстан Республикасында формалашкан “Алга” һәм “Тимер” батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән гражданнар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) һәм гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар тарафыннан хәрби хезмәт үтәү чорына 2022 елның 1 октябреннән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе башлыгы И.Ф. Шакировка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын
башкаручы, Җитәкче урынбасары –
Саба муниципаль районы Башкарма
комитеты аппараты җитәкчесе М.Р. Кәримов